**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1463**
**25.03.2020**

Җәйге спорт сезоны ачылуга багышланган шосседа велоспорт буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ачык чемпионатын һәм беренчелеген үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Җәйге спорт сезоны ачылуга багышланган шосседа велоспорт буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ачык чемпионаты һәм беренчелеге үткәрелү уңаеннан, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Законының 27 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2020 елның 25 апрелендә 10.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр, 2020 елның 26 апрелендә 10.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1) Металлургическая урамы буенча Техническая урамыннан Моторная урамына кадәрге автомобиль юлы участогында;

2) Моторная урамы буенча Металлургическая урамыннан Промышленная урамына кадәрге автомобиль юлы участогында.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыруны тәэмин итәргә.

4. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә:

1) әлеге карарны «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә;

2) транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне һәм автомобиль юлларын ябу өчен кирәкле йөк транспорты бирүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов